ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 008C52E957FFBDA9AC36C5500CFECDCD15
Владелец: Ханафеев Ильнур Мухаметович
Действителен с 19.08.2024 до 12.11.2025

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Средняя общеобразовательная школа №4 г. Мамадыш»
Мамадышского муниципального района Республики Татарстан

| Рассмотрено | Согласовано | Утверждаю |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УР | Директор МБОУ «СОШ №4 г.Мамадыш |
| МБОУ «СОШ №4 г.Мамадыш» | МБОУ «СОШ №4 г.Мамадыш» | ______________И.М. Ханафеев |
| _______ ___ / Д. Ф. Шакирзянова/ | _________З.М.Габдрахманова | Приказ №95 от 29 августа 2025года |
| Протокол №1 от 29 августа 2025 года | 29 августа 2025года | |

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
МБОУ « СОШ №4 г.Мамадыш»
по учебному курсу « Татарский язык » в 3а классе
учителя татарского языка и литературы
первой квалификационной категории
Юсуповой Нурфии Гиниятовны
Срок реализации: 1год

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
Протокол №1
От «29» августа 2025г.

2025-2026 учебный год

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен төгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Урта белем бирү баскычында телгә өйрәтү, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар, презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре****:*

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*****:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

## Эчтәлек

**Балалар фольклоры.**

Халык авыз иҗаты турында белешмә бирү. Балалар фольклоры (бишек җырлары,табышмаклар,тизәйткечләр,мәкальләр һ.б.) белән танышу.  Башка халык авыз иҗаты белән чагыштыру. Мәкальләр һәм әйтемнәр.Мәкальнең акыл бирү,сөйләмне матурлау өчен кулланылуы.Мәкальләрнең тематикасы. Мәкаль белән әйтемнең аермасы.Татар мәкальләре һәм әйтемнәрнең русча эквивалентлары.

**Татар халык җырлары.**

Татар халык җырлары белән таныштыру.Халык җырларының авторы халык булуы.Аларның вариантлылыгы.Халык җырларының жанрлары йола җырлары,аларның килеп чыгу үзенчәлеге. Аларның да халык җыры кебек яратып җырлануы,киң таралган булуы.”Халык моңнары:җырлата да елата да...”темасы буенча аңлап уку.

**Татар халык әкиятләре.**

Халык әкиятләре белән таныштыру.

**Милли киемнәр.**

Татар халкының милли киемнәре белән танышыру.Кием әдәпләре турында әңгәмә оештыру.

**Милли уеннар.**
Татар халкының милли уеннары белән таныштыру.Аларны уйнау,сәхнәләштерү.
**Татар халык бәйрәмнәре.**
Татар халык бәйрәмнәре белән таныштыру.
**Милли ризыклар**
Татар халык ашлары турында әңгәмә оештыру.Табын әдәпләре.Кунак чвкыру,кунакка бару темасына диалоглар.Мәктәп ашанәсе пешекчесе белән тыгыз элемтәдә булу

Лист согласования к документу № 11 от 09.10.2025
Инициатор согласования: Ханафеев И.М. Директор
Согласование инициировано: 09.10.2025 12:24

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ханафеев И.М. | | Подписано 09.10.2025 - 12:25 | - |